**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул. Клубная, д. 1а, с. Кутема,
Черемшанский район, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КУТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Клуб урамы, 1- нче «а» йорт, Кутәмә
авылы,
Чирмешән районы, 423112

тел./факс +8(84396) 4-30-88
email:Kut.Cmn2@tatar.ru

---

№64 10.06.2022 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Кутәмә авыл җирлеге Советы
карары

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кутәмә авыл җирлеге Советының 2017 елның 2 августындагы 60 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кутәмә авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кутәмә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кутәмә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кутәмә авыл җирлеге Советының 2017 елның 2 августындагы 60 номерлы "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кутәмә авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында" карарына (2017 елның 11 октябрендәге 67 номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 110 номерлы, 2019 елның 15 мартындагы 119 номерлы, 2021 елның 24 сентябрендәге 34 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «территорияне төзекләндерү - гражданнарның яшәү шартларын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга, торак пунктларның территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелешләрне, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне карап тотуга юнәлдерелгән, муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру буенча эшчәнлек»;»

1.2. 125 пунктның 14 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләрен, шул исәптән палаткалар, киосклар, лареклар, мини-базарлар, павильоннар, җәйге кафелар, җитештерү объектларын, автомобильләрне, көнкүреш техникасын, аяк киемен вак-төяк ремонтлау предприятиеләрен, шулай ук автостоянкалар, кунакханәдән кала урнаштыру.

Тиешле тәртиптә төзелгән һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләренең милекчеләре, Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, аларга стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында карар кабул итәләр.».

1.3. 183 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «хайваннар авыруларын кисәтүне һәм хайваннар продукциясенә ветеринария - санитария мөнәсәбәтендә куркынычсызлыкны тәэмин итүче хуҗалык һәм ветеринария чараларын гамәлгә ашыру, әйләнә-тирә мохитнең терлекчелек калдыклары белән пычрануына юл куймау, шулай ук ел саен яңадан теркәлү чорында мәҗбүри дәвалау-профилактика чаралары үткәрү»;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (pravo.tatarsnan.ru) һәм мәгълүмати стендларда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Күтәмә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Хәйруллин С.Н.